| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 23 декабрь г.Казань № 1127

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасындагы социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга торак урыннары бирү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасындагы социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга торак урыннары бирү тәртибен расларга.

2. «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә торган махсуслаштырылган оешма торак урыннары бирү буенча вәкаләтле оешма булып тора дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга бирү өчен билгеләнгән торак урыннары махсуслаштырылган оешма идарәсенең югары коллегиаль органы тарафыннан килештерелгән күләмдә бүленә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 23 декабрь, 1127 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Иннополис шәһәре территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы,
Татарстан Республикасындагы социаль ипотека системасында торак шартларын
яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга торак урыннар бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга социаль ипотека системасында торак урыннар бирү юлы белән торак урыннар бирү механизмын билгели.

2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

махсуслаштырылган оешма – «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын турыдан-туры гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан әлеге Закон нигезендә төзелгән яки вәкаләт бирелгән коммерциягә карамаган республика оешмасы яки орган;

гариза бирүче – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую максаты белән, гаилә әгъзасы булып торган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаилә исеменнән (яисә никахлашмаган булса үз исеменнән) гариза бирүче Россия Федерациясе гражданы;

гариза бирүченең гаилә әгъзалары – аның белән бергә яшәүче балалары һәм ире (хатыны), шулай ук башка туганнары һәм тәрбиягә алынган эшкә яраксыз затлар, әгәр алар гариза бирүче тарафыннан үз гаилә әгъзалары буларак йортка кертелгән булса;

социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую нормасы – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә торак урын сайлап алу урыны буенча гариза бирүче гаиләсенең бер әгъзасына туры килә торган торак хокуклары объектларындагы гомуми мәйдан күләме;

махсуслаштырылган оешма реестры – социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә алынган гражданнар реестры;

алдан җыела торган акча – төзелеш объектын эксплуатацияләүгә тапшырганга кадәр өстенлекле сайлап алу хокукында өлешләп фатир сатып алу максаты белән гариза бирүче тарафыннан җыелып бара торган акча. Алдан акча җыю тәртибе ирекле булып тора һәм гариза бирүченең үзе тарафыннан фатирны сайлап алуның өстенлекле хокукыннан файдалану нияте булганда, шулай ук алдан җыела торган акчаны махсуслаштырылган оешманың исәп-хисап счетына кертү шарты белән ай саен

түләнә торган түләүләрне өлешләп түләү вакытын озайту мөмкинлеге белән билгеләнә;

беренчел кертем – гариза бирүче тарафыннан социаль ипотека шартнамәсе төзелгән вакытта кертелә торган, катнашучының торак урын сатып алу хокукын тәэмин итә торган акча.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую нормасы торак урын сайлап алу урыны буенча гаиләнең бер әгъзасына гомуми мәйданның кимендә 18 квадрат метры күләмендә билгеләнә.

4. Торак хокуклары объектларында гариза бирүче гаиләсенең бер әгъзасына туры килә торган гомуми мәйданның күләмен исәпләп чыгарганда, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча торак пункт территориясендә гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының үз милкендәге һәм (яки) наем шартнамәсе буенча барлык файдаланудагы торак урыннар (алардагы өлешләре), шулай ук мондый урын милекчесе тарафыннан гаилә әгъзаларына, аларны үз гаилә әгъзасы буларак йортка кертү юлы белән, даими яшәү хокукы бирелгән торак урын исәпкә алына; шул ук вакытта әлеге торак урыннарның бергә кушып исәпләнгән гомуми мәйданы күләме бу торак урыннардан файдаланучы гаиләнең барлык әгъзалары (торак урын милекчесен кертеп) санына, аларның бергә яшәү (теркәлү) фактына карамыйча, пропорциональ рәвештә исәпләп чыгарылырга тиеш.

5. Гаризада күрсәтелгән гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының торак хокуклары объектлары турындагы мәгълүматлар Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органы тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә тикшерелә. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында һәм җирле үзидарә органнары карамагында торак хокуклары объектлары турында мәгълүматлар булмаганда, гариза бирүче үзенең, аның гаилә әгъзаларының күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документларны (торак урынына милек хокукы турында таныклык, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, бүләк итү шартнамәсе һ.б.) яки аларның нотариаль таныкланган күчермәләрен тапшыра.

6. Гариза бирүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән гаилә әгъзаларының, торак урында яшәүче башка гражданның яшәү (булу) урыны турындагы мәгълүматларны һәм граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турындагы мәгълүматларны тикшерү максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органы, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, Россия Федерациясе чикләрендә гариза бирүченең булу урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәүне исәпкә алуның база дәүләт мәгълүмат ресурсына һәм Граждан хәле актлары язмаларының бердәм дәүләт реестрына электрон документ формасында ведомствоара рәсми сораулар җибәрә. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органы, әлеге мәгълүматларны алганнан соң, аларны тикшерүне гамәлгә ашыра.

7. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую түбәндәге шартларны үтәп гамәлгә ашырыла:

гариза бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырылу;

гаиләнең һәр әгъзасына гомуми яшәү минимумын тәэмин итә торган һәм торак урыннарны милеккә сатып алу буенча ай саен түләнә торган агымдагы түләүләрне үз вакытында каплауны гарантияли торган гаиләнең бер әгъзасына айлык җыелма керем булу;

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендәге торак хокуклары объектларында гариза бирүче гаиләсенең бер әгъзасына гомуми мәйдан белән тәэмин ителешнең җыелма дәрәҗәсе әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую нормасыннан кимрәк булу;

гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының махсуслаштырылган оешма белән төзелгән шартнамәләр буенча гражданнарның аерым категорияләрен торак урын белән тәэмин итү буенча федераль һәм республика программалары буенча элек сатып алынган торак урын бәясен түләү буенча бурычлары булмау, шул исәптән аңа түләү максатларында махсуслаштырылган оешма белән төзелгән шартнамә буенча алынган максатчан акчалата заем тулысынча кире кайтарылу.

8. Гариза бирүче, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән исемлек буенча гариза бирүче тарафыннан бирелергә тиешле документларны теркәп, әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча гариза тапшыра һәм, барлык кирәкле мәгълүматларны күрсәтеп, әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасында бирелгән форма буенча гариза бирүче анкетасын тутыра.

Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую өчен гариза бирүчедән гаризалар кабул итү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органы тарафыннан;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк аша;

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә.

Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую турындагы гаризаларны карап тикшерү гариза бирелгән көннән алып 30 көннән артмаган срок эчендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Гариза бирүчегә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән документларны алу турында хәбәрнамә җибәрелә, анда аларның исемлеге һәм алыну датасы күрсәтелә.

9. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органы исәп эшен формалаштыра, җәмәгатьчелек торак комиссиясендә исәпкә кую турындагы гаризаларны карап тикшерә һәм, гариза бирелгән көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 6 һәм 7 нче кушымталары нигезендә исәпкә кую яки исәпкә куюдан баш тарту турында карар

чыгара.

Гариза бирүчегә түбәндәге очракларда социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә куюдан баш тартыла:

әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән шартлар нигезендә социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую хокукын расламый торган документлар тапшырылганда;

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар булмаганда яки алар тулысынча тутырылмаганда;

гаризада һәм тапшырылган документларда күрсәтелгән мәгълүматларга туры килми торган белешмә ачыкланганда;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булганда;

махсуслаштырылган оешма белән төзелгән шартнамәләр нигезендә аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итүнең федераль һәм республика программалары буенча элек сатып алынган торак урынның кыйммәте өчен тулысынча түләнмәгәндә, шул исәптән аңа түләү өчен махсуслаштырылган оешма белән төзелгән шартнамә нигезендә алынган максатчан акчалата заем тулысынча кире кайтарылмаганда.

Исәпкә алу эшен теркәү өчен нигез – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органының әлеге Тәртипкә 6 нчы кушымтада бирелгән форма буенча гариза бирүчегә уникаль исәпкә алу коды бирелгән исәпкә кую турында боерыгы.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органының исәпкә кую турындагы боерыгы, әлеге Тәртипнең 5 нче кушымтасы нигезендә тутырылган, әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасында бирелгән форма буенча социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнар исемлеге, исәпкә куелган көннән алып 30 көн эчендә, махсуслаштырылган оешмага җибәрелә. Әлеге документларны тапшыру документлар рәвешендәге кәгазь чыганакларда һәм (яки) «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә гамәлгә ашырыла.

10. Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнар исемлекләре әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтасында бирелгән форма буенча алып барыла һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органы тарафыннан даими нигездә эш хәлендә (шул исәптән исемлекләрдән төшереп калдыру) тотыла.

11. Махсуслаштырылган оешма Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органыннан социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнар исемлеген, шулай ук әлеге Тәртипнең 9 пунктындагы тугызынчы абзацында күрсәтелгән документларны кабул итә һәм аларга әлеге документлар кабул ителгән көннән алып 15 көн эчендә анализ ясый һәм аларны махсуслаштырылган оешма реестрына кертү турында карар кабул итә яки Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органына гариза бирүчеләрнең

тәкъдим ителгән исемлекләрдән әлеге Тәртип таләпләренә туры килми торган исемлеген, махсуслаштырылган оешма реестрына кертүдән баш тарту нигезләмәсен теркәп, кире кайтара.

12. Махсуслаштырылган оешма тарафыннан әлеге Тәртипнең 9 пунктындагы тугызынчы абзацында күрсәтелгән документларны кире кайтару Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органы өчен гариза бирүчене исәптән төшерү өчен нигез булып тора, бу хакта мондый карар кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән, аны исәптән төшерү нигезләрен күрсәтеп, хәбәр ителә.

13. Гариза бирүченең торак шартларын яхшыртуга хокукы аны махсуслаштырылган оешма реестрына кертелгән вакыттан алып барлыкка килә, махсуслаштырылган оешма эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бу хакта, шулай ук махсуслаштырылган оешма реестрына кертү турында хәбәрнамә алган көннән 90 көн эчендә махсуслаштырылган оешма белән социаль ипотека шартнамәсен төзү кирәклеге турында гариза бирүчегә язмача хәбәр итә.

14. Гариза бирүченең социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга хокукы барлыкка килү вакытыннан алып, гариза бирүче махсуслаштырылган оешма реестрына кертү турында хәбәрнамә алган көннән 90 көн эчендә махсуслаштырылган оешма белән социаль ипотека шартнамәсе төзергә һәм һәм узган ел өчен төзелгән махсуслаштырылган оешманың гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән кыйммәте күләменнән кимендә 11 процент беренчел тупланмаларның айлык түләүләрен башкарырга тиеш.

Беренчел тупланмалар өчен ай саен түләнә торган түләүләр күләме турында һәм узган ел өчен төзелгән махсуслаштырылган оешманың гомуми торак мәйданының бер квадрат метрын сату өчен уртача исәпләнгән кыйммәтенең күләме турында мәгълүмат чираттагы ел башында махсуслаштырылган оешманың рәсми сайтында урнаштырыла.

15. Әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә гаризада һәм әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендә гариза бирүче анкетасында үзгәрешләр булганда, гариза бирүче алар турында язма рәвештә исәпкә кую урыны буенча җирле үзидарә органнарына 30 көн эчендә хәбәр итәргә тиеш.

16. Гариза бирүче торак урын сайлап алына торган календарь елда һәм торак урын сайлап алу беркетмәсенә кул куйганга кадәр социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәменә хокукын раслау максат белән исәпкә кую урыны буенча җирле үзидарә органында яңадан теркәлергә тиеш.

Яңадан теркәлү исәпкә куелу кебек тәртиптә башкарыла.

Әгәр гариза бирүче тарафыннан исәпкә куелу датасыннан соң ел дәвамында торак урын сайлап алынган булса, яңадан теркәлү таләп ителми.

17. Гариза бирүченең махсуслаштырылган оешма реестрында тору хокукы гаилә тарафыннан торак урын сайлап алынганга кадәр, түбәндәге очраклардан тыш, саклана:

гаризада һәм исәпкә алырга нигез булган, тапшырылган документларда күрсәтелгән мәгълүматларга туры килми торган мәгълүматлар ачыкланганда;

исәпкә куелганда вазыйфаи затларның хокуксыз гамәлләр кылу очраклары ачыкланганда;

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис

шәһәре территориясендә торак урын сайлап алу буенча хезмәт эшчәнлеген туктату турында мәгълүмат ачыкланганда;

аның тарафыннан әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган нигезләр бетерелгәндә;

әлеге Тәртипнең 8 кушымтасында бирелгән форма буенча исәптән төшерү турында гариза бирелгәндә;

яңадан теркәлү барышында гариза бирүченең социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәме хокукын расламый торган белешмәләр ачыкланганда;

гариза бирүче тарафыннан махсуслаштырылган оешма реестрына кертү турында хәбәрнамә алынган көннән 90 көн эчендә социаль ипотека шартнамәсе төзелмәгәндә;

ай саен түләнә торган түләүләрне башкару буенча шартнамә шартлары алты айдан артык үтәлмәгәндә;

якларның килешүе буенча шартнамә өзелүгә бәйле рәвештә, махсуслаштырылган оешма реестрыннан төшереп калдырылганда.

Әлеге пунктта күрсәтелгән очраклар ачыкланганда, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органы бу турыда мондый очрак билгеле булган көннән 10 көн эчендә махсус оешмага хәбәр итә.

Махсуслаштырылган оешма реестрыннан төшереп калдыру махсуслаштырылган оешманың карары белән гамәлгә ашырыла; ул карар кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органына, төшереп калдыру сәбәбен күрсәтеп, язма рәвештә мәҗбүри хәбәр ителә.

Махсуслаштырылган оешма хәбәрнамәсе алынганнан соң, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органы тиешле хәбәрнамә алынган көннән 10 көн эчендә гариза бирүчене исәптән төшерү турында карар кабул итә.

18. Әлеге Тәртип нигезендә исәпкә алынган гариза бирүчеләргә социаль ипотека системасында торак төзелешенә бүлеп бирелә торган максатчан акча хисабына төзелгән торак йортлардан торак урыннар бүленеше ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган квоталар нигезендә гражданнар категорияләре буенча гамәлгә ашырыла.

19. Гариза бирүчеләргә бирелә торган торак урыннарның гомуми мәйданы нормативлары түбәндәгечә тәшкил итә:

ялгыз яшәүче граждан өчен – 33 квадрат метр;

ике кешелек гаилә өчен – 42 квадрат метр;

өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – бер кешегә 18шәр квадрат метр;

20. Исәпкә куелганнан соң гариза бирүченең гаиләсендә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда аның торак урын бәясен түләү өчен 200 мең сум күләмендә, әмма бала туу, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алу вакытына торак урынның түләнмәгән өлеше яки төп бурычның түләнмәгән өлеше бәясеннән артмаган күләмдә дәүләт ярдәменә хокукы барлыкка килә.

21. Гариза бирүче исәпкә кую урыны буенча гына торак урын сайлап алу хокукына ия.

22. Торак урын бирү конкурс нәтиҗәләре буенча торак урын сайлап алуда катнашу тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

23. Социаль ипотека шартнамәсе төзегән һәм әлеге Тәртипнең 19 пунктында билгеләнгән торак урыннарның гомуми мәйданы нормативлары нигезендә бирелә торган торак урын кыйммәтеннән кимендә 10 процент беренчел кертем җыйган гариза бирүчеләргә конкурста катнашырга рөхсәт ителә.

24. Торак урын сайлап алу конкурсы гариза бирүчеләр тарафыннан билгеләнгән квоталар чикләрендә үзләренең булачак торак урыннарын билгеләү максатларында уздырыла.

25. Конкурста катнашу өчен гариза бирүче социаль ипотека шартнамәсендә күрсәтелгән индивидуаль номер һәм пароль буенча махсуслаштырылган оешманың «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) электрон рәвештә заявка тутыра.

Заявкада гариза бирүче өстенлекләр кимү тәртибендә сайлап алына торган торак урыннар исемлеген билгели. Заявка рәсми сайтта теркәлә.

26. Конкурста җиңүче итеп электрон рәвештә билгеләнә торган иң зур рейтингка ия гариза бирүче таныла.

27. Гариза бирүченең рейтингы, конкурска йомгаклар ясау көненә кадәр соңгы 10 көнне кертмичә, махсуслаштырылган оешма счетында аларның булу көннәре санына тапкырланган, меңләгән сумда беренчел тупланмалар суммасына тигез булган сан буларак билгеләнә.

28. Махсуслаштырылган оешманың конкурста җиңүчеләрне билгеләү турында карары конкурс йомгаклары турындагы хисапта рәсмиләштерелә. Мәгълүмат махсуслаштырылган оешманың рәсми сайтында чагылдырыла.

29. Конкурс йомгаклары турында хисап расланган көннән алып 10 эш көне эчендә гариза бирүче торак урын сайлап алу буенча беренчел беркетмәгә кул куя.

Гариза бирүче тарафыннан социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга хокукы раслану һәм торак йорт файдалануга тапшырылу шарты белән Махсуслаштырылган оешманың попечительләр советы тарафыннан расланган форма буенча торак урын сайлап алу беркетмәсе рәсмиләштерелә. Торак урын сайлап алу беркетмәсе социаль ипотека шартнамәсенең аерылгысыз бер өлеше булып тора һәм конкурста җиңүченең сайлап алынган торак урынына күчену һәм аннан файдалану хокукын раслый.

Торак урын сайлап алу беркетмәсенә гариза бирүче тарафыннан сайлап алынган торак урын урнашкан торак йорт файдалануга тапшырылганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча имза куела.

Гариза бирүче тарафыннан торак урын сайлап алу беркетмәсенә 30 көн календарь көн эчендә торак урын сайлап алу конкурсы нәтиҗәләре һәм торак урын сайлап алуның беренчел беркетмәсе гамәлдән чыгарыла.

Объектны файдалануга тапшыру датасы һәм сайлап алынган торак урынга күчену мөмкинлеге турында мәгълүмат махсуслаштырылган оешма тарафыннан объект файдалануга тапшырылу датасыннан алып 10 календарь көн эчендә рәсми сайтта урнаштырыла.

30. Сатып алына торган торак урынның бер квадрат метрының башлангыч бәясе махсуслаштырылган оешма тарафыннан билгеләнә. Торак урынның түләнмәгән өлеше бәясе объект файдалануга кертелгән көннән алып ай саен елына җиде процент (аена 7/12 процент) исәбеннән чыгып арта.

Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасы үзгәргән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты торак урынның түләнмәгән өлеше кыйммәте артуга кертелә торган еллык ставканы үзгәртү мөмкинлеге турындагы мәсьәләне карый.

31. Торак урынны милеккә сатып алу буенча ай саен түләнә торган агымдагы түләүләрне өлешләп түләү 15 елдан алып 28,5 елга кадәр тәшкил итә.

32. Өлешләп түләү өчен бирелгән торак урыннарны милеккә сатып алу буенча ай саен түләнә торган агымдагы түләүләр торак урынны сайлап алу беркетмәсе рәсмиләштерелгән вакытта торак урынның сатып алынмаган мәйданына тапкырланган һәм айлар буенча өлешләп түләү срогына бүленгән торак урынның бер квадрат метры кыйммәтеннән чыгып исәпләнә.

33. Гариза бирүче торак урын сайлап алу беркетмәсен рәсмиләштергән вакыттан торак урынның гомуми мәйданының түләнмәгән өлеше өчен наем түли.

34. Гариза бирүче махсуслаштырылган оешма белән төзелгән социаль ипотека шартнамәсе буенча сатып алынган торак урын кыйммәтен тулысынча түләп бетергәннән соң, гариза бирүче социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбеннән төшерелергә тиеш.

35. Гаилә бирүче социаль ипотека шартнамәсе буенча бурычның калган өлешен, махсуслаштырылган оешма белән сайлап алынган торак урынны сатып алу-сату турында шартнамә төзеп, кредит оешмаларының заем акчасы исәбеннән түләп бетерергә хокуклы, шул ук вакытта социаль ипотека шартнамәсе буенча моңа кадәр тупланган акча һәм дәүләт ярдәме буларак түләүләр сатып алу-сату шартнамәсе буенча беренчел кертем буларак күчерелә.

36. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре җирле үзидарә органы һәм махсуслаштырылган оешма карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

_______________________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасындагы социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга торак урыннары бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

______________________________________
(район, шәһәр исеме)
______________________________________
___ җирле үзидарә органы җитәкчесенә
______________________________________
(шәһәрдә, поселокта, авылда адрес буенча яшәүче:)
______________________________________
(почта индексы, тулы адресы,
______________________________________
элемтәгә керү өчен телефоны)
______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме
______________________________ тан (дан)
(соңгысы – булганда) тулысынча)
______________________________ нан (нән)
(көне, ае, елы)

Гариза

________________________________________________________________________
(торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булу сәбәпләрен күрсәтергә)
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
________________________________________________________________ бәйле рәвештә

Сездән мине социаль ипотека системасында торак шартларын яхшырту өчен ____ кеше составында гаилә белән исәпкә алуыгызны сорыйм.

Билгеләнгән форма буенча тутырыла торган гариза өчен социаль ипотека системасында торак шартларын яхшырту өчен минем гаиләмне исәпкә кую өчен кирәкле белешмәләр бирелә торган анкета теркәлә.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары җирле үзидарә органнары тарафыннан гаризада һәм анкетада күрсәтелгән белешмәләрне тикшерүгә, алар тарафыннан рәсми сорау бирүгә, шулай ук махсуслаштырылган оешма тарафыннан исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документларны тикшерүгә ризалык бирәбез.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, безне исәпкә алган очракта, гаризада

күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә бер ай эчендә алар турында исәпкә алу урыны буенча җирле үзидарә органнарына язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш дип кисәтелде.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, гаризада күрсәтелгәннәргә туры килми торган мәгълүматлар ачыкланган очракта, безне закон белән билгеләнгән тәртиптә исәптән төшерүгә риза.

Моның белән мин тиешле салым органнарында һәм күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу органнарында минем керемнәрем һәм милек хокукында минеке булган мөлкәт турындагы мәгълүматларны тикшерергә ризалык бирәм.

Гаризаны карау нәтиҗәләре турында түбәндәге ысул белән хәбәр итүегезне сорыйбыз:

☐ язма рәвештә;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталының шәхси кабинетында электрон рәвештә;

☐ дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк аша.

Гариза бирүче:

______________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) тулысынча, имза)

Гаиләнең хокукка сәләтле әгъзалары:

1.____________________________________________________________

2.____________________________________________________________

3.____________________________________________________________

4.____________________________________________________________

5.____________________________________________________________

6.____________________________________________________________

(гаиләнең хокукка сәләтле барлык әгъзаларының имзалары)

20__ ел, «___» ____________________

(датаны тутырып язырга)

______________________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасындагы социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга торак урыннары бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Гариза бирүчене һәм аның гаиләсен социаль ипотека системасында торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алу турында мәсьәләне карап тикшерүгә кирәкле документлар исемлеге

1. Гражданның җирле үзидарә органы җитәкчесе исеменә гаризасы.

2. Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданы, гариза бирүче һәм аның 14 яшьтән зуррак гаилә әгъзалары шәхесен таныклый торган документ.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәрендә теркәлгән булса, торак урынның торак һәм гомуми мәйданнары күрсәтелгән финанс-хисап счеты.

4. Гаилә составын билгели торган документлар:

1) гариза бирүченең 14 яше тулмаган һәр гаилә әгъзасы өчен туу турында таныклык;

2) никахлашу факты булганда гариза бирүче һәм (яки) аның гаилә әгъзалары өчен никахлашу турында таныклык;

3) ата булуны билгеләү факты булганда ата булуны билгеләү турында таныклык;

4) әгәр никах таркалган вакыттан биш ел үтмәгән булса, әлеге чорда никахны таркату факты булганда, аерылышу турында таныклык;

5) фамилиясен, исемен, атасының исемен алыштыру факты булганда фамилиясен, исемен, атасының исемен алыштыру турында таныклык;

6) гаилә составын раслау өчен үлем факты булганда үлем турында таныклык;

7) суд карары булганда ата булуны билгеләү турында яки ата булуны тану фактын билгеләү турында законлы көчкә кергән суд карары (суд карарын кабул иткән суд тарафыннан таныкланган күчермә);

8) суд карары булганда гариза бирүчегә һәм (яки) гариза бирүченең гаилә әгъзаларына карата туганлык мөнәсәбәтләрен билгеләү яки туктату, ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү, үлгән дип тану, хәбәрсез югалып тору дип тану турында законлы көчкә кергән суд карары (суд карарын кабул иткән суд тарафыннан таныкланган күчермә);

9) чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе (булганда);

10) Россия Федерациясенең граждан хәле актларын теркәү органнары яки консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык (булганда).

5. Торак шартларын раслый торган документлар:

1) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан үзендә булган (элек булган) күчемсез мөлкәт объектларына аерым затның хокуклары турында өземтә (соңгы биш елга);

2) гариза бирүченеке, аның гаилә әгъзаларыныкы булган, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында торак урыннарга хокуклар теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документлар (торак урынга һәм (яки) җир кишәрлегенә милек хокукы турында таныклык, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, бүләк итү шартнамәсе һ.б.) яки аларның нотариуста таныкланган күчермәләре;

3) Ордер (наем, өстәмә наем, аренда, субаренда шартнамәсе);

4) әгәр торак урынга хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәсә, торак урынның (фатирның) техник планы яки техник паспорты;

5) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез мөлкәт объекты турында өземтә;

6) торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану турында мәгълүматлар.

6. Керемнәрнең төрләрен һәм күләмен раслый торган документлар:

1) хезмәт кенәгәсе (барлык битләрнең эш бирүче тарафыннан расланган күчермәсе) һәм (яки) тиешле рәвештә расланган кәгазь чыганакта яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.11 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар;

2) студентлар билеты яки уку урынын раслый торган башка документ (гаилә әгъзаларының укучылары өчен);

3) хәрби хезмәт үтү турында белешмә кәгазе;

4) һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучыларга, аспирантларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучыларга һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына, дини мәгариф оешмаларында белем алучыларга түләнә торган стипендия күләме яки әлеге категориядәге гражданнар медицина күрсәткечләре буенча академик ялда булган чорда аларга компенсация түләүләре күләме турында тиешле мәгариф оешмасы тарафыннан бирелгән белешмә кәгазе (тиешле түләүләрне ала торган (алган) затлар өчен);

5) физик затларның, шул исәптән махсус салым режимнарын куллanучы индивидуаль эшмәкәрләрнең керемнәре турында мәгълүматлар;

6) физик затлар файдасына иминият кертемнәрен түләүчеләр тарафыннан башкарылган түләүләр турында, пенсияләр, пособиеләр һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яки) Татарстан Республикасы законнары нигезендә түләүләр рәвешендә алынган башка социаль ярдәм чаралары турында мәгълүматлар;

7) пособиеләр билгеләү турында мәгълүматлар;

8) салым органнарында исәпкә куелу турында мәгълүматлар;

9) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлү турында мәгълүматлар;

10) иминият стажы турында мәгълүматлар;

11) опека һәм попечительлек органы актыннан опекун билгеләү турында мәгълүматлар.

7. Яшәү (тору) урыны турында мәгълүматлар.

8. Гаиләнең һәр әгъзасы өчен салым органының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлар булмау турында белешмә кәгазе.

9. Оешма хезмәткәрен социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә алу турында җирле үзидарә органы җитәкчесе адресына язылган оешма үтенечнамәсе.

10. Җирле үзидарә органы (оешма) тарафыннан расланган форма буенча шәхси (гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының) мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

Искәрмә. Әлеге исемлекнең 4 пунктындагы 1 – 6 пунктчаларында, 6 пунктындагы 1, 5, 6 пунктчаларында, 7, 8 пунктларында күрсәтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомствосы буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документлар (аларның күчермәләре яки алардагы мәгълүматлар), шул исәптән исәпкә кую буенча яңадан теркәлгәндә, җирле үзидарә органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән мөстәкыйль рәвештә соратып алына. Гариза бирүче әлеге документларны үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасындагы социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга торак урыннары бирү тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

Гариза бирүче анкетасы

1. Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме* ______________________________
(тулысынча)
______________________________________________________________________

2. ______________________________________________ адресы буенча яшим
(район, урам, йорт, фатир, бүлмә)
______________________________________________________________________
(элемтәгә керү өчен өй, эш телефонын күрсәтергә)

3. Шәхесне таныклый торган документ ______________________________________
(документ төре)
сериясе _______ номеры _______________ кем һәм кайчан бирелгән ________________
______________________________________________________________________

4. Туган көне __________________________________________________________
(көне, ае, елы)

5. Туган урыны _________________________________________________________

6. Салым түләүче идентификация номеры | | | | | | | | | | | | |
(барлык унике билгене күрсәтергә)

7. Эш урыны ___________________________________________________________
оешманың, бүлекнең тулы исемен, вазыйфаны күрсәтергә)
______________________________________________________________________
(әгәр гариза бирүче эшләмәсә, эш белән тәэмин ителмәү сәбәбен күрсәтергә)

8. Оешманың салым түләүче идентификация номеры | | | | | | | | | | | | |
(әгәр гариза бирүче эшләмәсә, күрсәткечтә нольләр куела, ягъни эшләмәүче өчен – 0 000 000 000)

9. Гаилә составы ________ кеше:

<table>
